**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**29 сентябрь, 2023 ел** **№ 322**

# Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 15 пункты, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 9, 10, 18-21 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 16 статьясы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Уставы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү проектына 2023 елның 04 сентябрендәге 10-53/10854 номерлы бәяләмәсе нигезендә, Татарстан Республики Высокогорского муниципального района Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының 2014 елның 31 мартындагы 340 номерлы карары (28.12.2016 №117, 28.12.2020 №50 карарлары редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына, аларга карата генераль планны әзерләү кирәклеге булмау турында карар кабул ителгән авыл җирлекләре чикләрендә урнашкан торак пунктлар чикләре турында белешмәләр өстәү өлешендә үзгәрешләр кертергә.
2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетына әлеге карарны территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында (https://fgistp.economy.gov.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Биектау муниципаль районының рәсми сайтында (http://vysokaya-gora.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Ф. Хисамутдинов

«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү турында» карарына материаллар белән территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында (https://fgistp.economy.gov.ru) УИН 9262200002020301202308071 танышырга мөмкин.